**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 21 март № 165

г. Казань

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зәй муниципаль районындагы «Шатлык» халыкка социаль ярдәм күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе структурасын оптималь-ләштерү турында

Татарстан Республикасы социаль яклау тармагы инфраструктурасын оптимальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зәй муниципаль районындагы «Шатлык» халыкка социаль ярдәм күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең (алга таба – «Шатлык» халыкка социаль ярдәм күрсәтү комплекслы үзәге) социаль-тернәкләндерү бүлеген 28 койка-урынга калдыру турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә «Шатлык» халыкка социаль ярдәм күрсәтү комплекслы үзәге структурасы тарафыннан әлеге учреждениене оптимальләштерү чараларын үткәргәндә хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә;

эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтенең оператив идарә итү хокукында «Шатлык» халыкка социаль ярдәм күрсәтү комплекслы үзәгенә беркетелгән аерым төрләреннән файдалану турында тәкъдимнәр тапшырырга, әлеге мөлкәт һәм даими вакыты чикләнмәгән файдалану хокукында «Шатлык» халыкка социаль ярдәм күрсәтү комплекслы үзәгенә беркетелгән җир кишәрлекләре исемлеген теркәп;

тиешле финанс елына һәм план чорына «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы буенча Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган акча кысаларында «Шатлык» халыкка социаль ярдәм күрсәтү комплексы үзәге тарафыннан дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә каралган чыгымнар өлешендә «Шатлык» халыкка социаль ярдәм күрсәтү комплексы үзәге структурасын оптимальләштерү белән бәйле чаралар үткәрүгә чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына законнарда билгеләнгән тәртиптә 60 көн эчендә элек «Шатлык» халыкка социаль ярдәм күрсәтү комплексы үзәгенә беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен һәм 120 көн эчендә элек «Шатлык» халыкка социаль ярдәм күрсәтү комплексы үзәгенә беркетелгән җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тапшырган исемлек нигезендә тапшыруны тәэмин итәргә.

4. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә әлеге карарның 2 һәм 3 пунктларында күрсәтелгән барлык чаралар тәмамланганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарны раслау турында» 2016 ел, 18 ноябрь, 849 нчы карарына тиешле үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каравына кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\165.docx